КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 сентябрь г.Казань № 936

Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 31 октябрь, 972 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 24 июнь, 510 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 23 июль, 615 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 25 февраль, 143 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин